КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 март г.Казань № 171

М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү турында

М.Җәлил исемендәге Республика премиясен бирү комитеты утырышы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2018 – 2019 еллар конкурсы йомгаклары буенча М.Җәлил исемендәге Республика премиясен түбәндәгеләргә бирергә:

«Һөнәр» бөтенроссия яшь режиссура фестивален оештырган һәм Татарстан Республикасының театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән өчен авторлар коллективына: «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең әдәби-драма бүлеге җитәкчесе Нияз Рәүф улы Игъламовка, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Илфир Илшат улы Якуповка;

Муса Җәлил иҗатын өйрәнүгә һәм пропагандалауга, дәреслекләр, уку-укыту программалары, укыту-методик әсбаплар һәм китаплар төзүгә зур өлеш керткән өчен шагыйрь, прозаик, публицист, педагог, галим-җәлилче Канәфи Габделбәр улы Бадыйковка;

артистның «Әлиф» («Зов начала») хореография спектаклендә эшләгәне өчен «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе балетмейстеры-куючысы Нурбәк Роберт улы Батуллинга;

югары һөнәри осталыгы, милли музыка сәнгатен актив пропагандалавы, концерт һәм башкару эшчәнлеге өчен «Созвездие – Йолдызлык» Татарстан Республикасы Төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасының сәнгать җитәкчесе Айдар Данил улы Сөләймановка.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин